МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.02.2021 г.Казань № 55

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 1 мартында 7571 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Конкурс конкурсларда катнашуга кертелгән Россия Федерациясе

гражданнарының (дәүләт граждан хезмәткәрләренең) һөнәри дәрәҗәсен, шулай ук аларның тиешле граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен (алга таба – квалификация таләпләре, кандидатларны бәяләү) бәяләүдән гыйбарәт.»;

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурсларны нәтиҗәле оештыру максатларында Министр карары буенча Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфаларының төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен берничә конкурс комиссиясе оештырылырга мөмкин.»;

2.4 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) ул вәкаләт биргән (шул исәптән Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегеннән һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырыла торган Министрлыкның структур бүлекчәсеннән дә) граждан хезмәткәрләре (алга таба – Министрлыкның структур бүлекчәсе вәкиле), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның граждан хезмәткәрләренең профессиональ хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә кадр технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булып торган, законнарда билгеләнгән тәртиптә министрның рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла торган вәкилләре керә. Конкурс комиссиясе составына кертелә торган Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет карарлары белән билгеләнә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бәйсез экспертның Министрлыкның конкурс комиссиясендә булуының гомуми вакыты өч елдан артмаска тиеш. Әлеге срок бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына беренче керткән вакыттан башлап исәпләнә. Әлеге бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына кабат кертү Конкурс комиссиясендә булу срогы тәмамлангач өч елдан соң гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү өчен) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

Кандидат белән турыдан-туры шәхси әңгәмә үткәрмичә генә конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү рөхсәт ителми.

Конкурс комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән, мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.»;

3.4 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);»;

җиденче абзацта «эш (хезмәт) урыны буенча» сүзләрен «хезмәт итү (эшләү) урыны буенча» сүзләренә алмаштырырга;

4.9 пунктта «конкурс комиссиясе бәяли» сүзләрен алда «һөнәри дәрәҗәсен» сүзләрен өстәргә;

4.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.»;

4.12 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һәр критерий өчен максималь балл – 25, минималь – 5.»;

4.13 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тест нәтиҗәләре буенча максималь балл – 100 тәшкил итә, иң азы – 60.»;

4.15 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.15. Кандидатның ахыргы баллы кандидатка конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан шәхси әңгәмә, конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә торган башка конкурс биремнәре нәтиҗәсендә куелган балларның һәм кандидатның тест һәм башка төрле аналогик, нәтиҗәләрнең формалаштырылган исәпләмәсен күздә тоткан конкурс биремнәрен үтәү йомгаклары буенча җыелган балларның уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.»;

икенче абзацында «аларның ахыргы балларын кимету тәртибендә» сүзләрен өстәргә;

Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында «(Белешмә өчен: максималь балл 100 балл тәшкил итә)» сүзләрен «(Белешмә өчен: балларның максималь саны 100 балл тәшкил итә)» сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында «(Белешмә өчен: максималь балл 100 балл тәшкил итә)» сүзләрен «(Белешмә өчен: балларның максималь саны 100 балл тәшкил итә)» сүзләренә алмаштырырга.

Министр Э.Ә. Зарипова